Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
## УНИВЕРСИТЕТ

12+

№4 (97)

20 февраль 2014 ел

# Бәйрәм белән, егетләр!





Влад Михневский фотолары

Ватанны саклаучылар көне уңаеннан уку йортыбызда тантаналы чара узды. Матур концерт номерлары белән үрелеп барган бәйрәмдә студентларның әлеге истәлекле датага багышланган стенгазеталары конкурсына, хәрби спорт уеннарына йомгак ясалды. Җиңүчеләр (фотода) дипломнар һәм кубоклар белән бүләкләнде. Хөрмәтле ветераннарыбыз һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар чараның төп кунаклары булдылар. Аларга ректор И.Гафуров исеменнән Рәхмәт хатлары тапшырылды.

## • Вакыйгалар эзеннән

**12-16 ФЕВРАЛЬ** көннәрендә «Волга» яшьләр үзәге базасында студентларның хезмәт отрядлары арасында Сочида уза торган XXII кышкы Олимпия уеннарына багышланган **КЫШКЫ РЕСПУБЛИКА СПАРТАКИАДАСЫ ҮТТЕ**. Республиканың башка шәһәрләреннән дә килгән барлыгы 11 команда көч сынашты. КФУ җыелма командасы данын яклаган студентлар барлык спорт төрләрендә дә югары нәтиҗә күрсәтеп, гомуми зачетта беренче урынны яулады.

• • • •

**13 ФЕВРАЛЬ** көнне КФУ ректоры **И.ГАФУРОВ** һәм Әстерхан дәүләт университеты ректоры **А.ЛУНЕВ** «Теория перевода: межкультурная/межъязыковая коммуникация» дип атлалган челтәрле магистратураны реализацияләүнең уртак формасы турындагы **КИЛЕШҮГӘ КУЛ КУЙДЫЛАР**. Килешү нигезендә тәрҗемә өлкәсендәгеэкспертларныһәмбелгечләрне җәлеп итү, КФУ укытучыларының стажировкаларын, ә студентларның практикаларын Европаның БМО институтларында үтү һәм студентларга өстәмә дистанцион белем бирү дә планлаштырыла.

• • • •

**14 ФЕВРАЛЬ** көнне КФУның 1нче аудиториясендә «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе рәисе **РАДИК БАТЫРШИН** «Телевизионный продюсер: миссия невыполнима?» лекциясе белән **ЧЫГЫШ ЯСАДЫ**, төрле видеофильмнар да тәкъдим итте. Сценарийлар белән эшләү принциплары, телевидение һәм продюсерлык серләре – лекциянең төп темалары иде.

• • • •

**15 ФЕВРАЛЬ** көнне Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында **«АЧЫК ИШЕКЛӘР» КӨНЕ БУЛДЫ**. Бу көнне абитуриентлар интститут һәм аның структурасы белән тулырак танышып, үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап алды. Абитуриентларга институт турында видеофильм да тәкъдим ителде.

• • • •

**18 ФЕВРАЛЬ** көнне **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Утырышта беренче булып контроль йөкләмәләрнең үтәлеше турында һәм 18-24 февраль аралыгында үткәреләчәк чаралар хакында административ эшчәнлек буенча проректор **А.ХАШОВ** җиткерде. «Инженерлык һәм идарә системаларын тикшерү» фәнни-тикшеренү лабораториясе җитәкчесе **А.МАХАНЬКО** инновация эшчәнлеге турында презентация тәкъдир итте.Чыгышта бу өлкәгә кагылган кече инновацион предприятиеләр, җиһазлар һәм фәнни эшчәнлек турында сүз алып барылды. Инновацион эшчәнлек буенча проректор **Н.КАШАПОВ** КФУдагы инженерлык белеме бирү һәм аның программалары белән таныштырды. Төп вузда барлыгы 17, Яр Чаллы институтында 96 инженерлык программалары бар. Аларны реализацияләү хакында институт директоры **М.ГАНИЕВ** сөйләде. Утырышта Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтының мәгълүмати технологияләр бүлеген булдыру идеясе белән институт директоры **Д.НУРГАЛИЕВ** чыгыш ясады. Бүлек эшчәнлеге структур бүлекчәнең фәнни, белем бирү эшчәнлеген IT-форматында оештырудан гыйбарәт булачак. Социаль һәм тәрбия эшләре буенча проректор **А.МЕЖВЕДИЛОВ** утырышта катнашучыларны студентлар советы эшчәнлеген оештыру һәм активлаштыру буенча РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы әзерләгән методик тәкъдимнәр белән таныштырды. Юридик факультет деканы **И.ТАРХАНОВ** һәм гражданлык һәм юридик хокук кафедрасы җитәкчесе К.Арсланов ТР Прокуратурасының КФУга дәүләт ярдәме проектына кагылышлы кисәтүләргә дә тукталды. Шулай ук утырыш барышында Н.И.Лобачевский ис. математика һәм механика институты директоры **В.ЧУГУНОВ** Н.И.Лобачевскийның туган көненә һәм математиклар көненә багышлап уздырылачак чаралар турында да сөйләде.

• • • •

**18 ФЕВРАЛЬ** көнне А.М.Бутлеров ис.химия институтында 2013 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2014 ел планнарына багышланган очрашуда икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор **М.САФИУЛЛИН**, фәнни эшчәнлек буенча проректор **Д.НУРГАЛИЕВ**, Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры **А.КИЯСОВ**, Физика институты директоры урынбасары **Д.ТАЮРСКИЙ**, ИТИС югары мәктәбе директоры **А.ХАСЬЯНОВ**, университетыбызның башка **ГАЛИМНӘРЕ КАТНАШТЫ**.

• • • •

**КФУның «ФЕДЕРАЛЬНЫЙ» ШТК КОМАНДАСЫ** XIX ТР ШТК телевизион фестиваленең **ГРАН-ПРИ ИЯСЕ БУЛДЫ**. Быел чарада барлыгы 50 команда көч сынашты. Һәр команда үзенең оригиналь программасын тәкъдим итте.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Ватанны саклаучылар көне

# Зыялы нәсел дәвамчысы

*Исәнмесез, хөрмәтле редакция хезмәткәрләре!*
*Мин сезнең газетаны интернет аша укып барам, тарих укытучысы буларак, кирәкле мәгълүматлар алам. Газетагыз бик матур бизәлешле, язмалары да мәгънәле. 1998 елдан Саба районы белән хезмәттәшлек итүче, университетның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты профессоры Альберт Әхмәтҗан улы Борһанов турында сезгә бер язма тәкъдим итәм, аны газетагызда бастыра алсагыз, бик рәхмәтле булыр идем. Сезгә иҗади уңышлар теләп, ихтирам белән Саба районы Юлбат урта мәктәбенең тарих укытучысы* ***Илдар Сафин.***

Узган ел ахырында КФУ профессоры Альберт Әхмәтҗан улы Борһановның туган авылы – Чиләбе өлкәсе, Коншак районы Усть-Багаряк (Түбән авыл) – төзелүгә 305 ел тулуга багышлап язылган «Көньяк Уралда татар авылы» дигән китабы басылып чыкты. Автор иң элек туган авылы һәм Сөнәр (Синара) елгасы тирәсендәге авылларның археологик истәлекләре турында сөйли, аларга фәнни анлатмалар бирә. Билгеле, китапның төп өлешендә шушы яктан чыккан кешеләрнең фидакяр хезмәте, авыл тарихын чагылдырган шанлы вакыйгалар турында сөйләнә. Авылларында мәктәп ачылуга да туксан ел тулган икән. Альберт әфәнде «Минем кадерле укытучыларым», – дип, үзенә белем биргән укытучыларын чын йөрәктән чыккан җылы хисләр белән иске ала. «Минем киләчәктә тарихчы булып китүемдә алар зур роль уйнады», – ди автор.



Әменә әнисе ягыннан бабасы Җамалетдин Сираҗетдин улы Камалов (1883-1937) турында оныгы Альберт зур горурлык хисләре белән яза. Дөрестән дә бик зыялы, үз авылларының чын патриоты була аның бабасы. Ярлы гаиләдән чыккан булуына карамастан, башта авыл мәдрәсәсен тәмамлый. 1902-1905 елларда дүрт класслы училище тәмамлап, башлангыч сыйныфлар укытучысы дигән диплом ала. Алга таба да үз белемен күтәрү өчен, Уфа шәһәрендә, Төркиядә, ә соңыннан Екатеринбургтагы Мөселман институтында укый. Октябрь революциясенә кадәр Шадрин өязенең Земство Идарәсе секретаре итеп сайлана. Революция, гражданнар сугышы елларында «Идел-Урал Штаты» төзү идеясен яклап чыга. Бу идеяне татар, башкорт халкы арасында тарату өчен, актив эшчәнлек алып бара. 1922 елда үз авылларында беренче татар-башкорт башлангыч мәктәбен ача. Аның инициативасы белән соңыннан мәктәп сигезьеллык итеп үзгәртелә. Җамалетдин Камалов аның беренче директоры була, укучыларга тарих, география фәннәреннән белем бирә. Ул бик тырыш, белемгә омтылучан кеше була. 54 яшендә Чиләбе педагогия институтының тарих факультетына читтән торып укырга керә. Кызганычка каршы, бер генә семестр укып кала. 1937 елда Җамалетдинны, әләкчеләр доносы белән, революциягә кадәр земство секретаре булып эшләгәнлеген истә тотып, контрреволюцион эштә гаепләп, чит ил шпионы дип, үзенең җиде иптәше белән бер гаепсезгә кулга алалар, атып үтерәләр.

Ә бүген исә зыялы нәселнең дәвамчысы – оныгы Альберт – аның башлаган эшнен лаеклы дәвам итә. Бабасы нигез салган мәктәпне тәмамлап, ул да Чиләбе дәүләт институтының тарих бүлегенә укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң, М.В.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетында аспирантурада укып, тарихчы-археолог һәм көнчыгыш илләрен өйрәнүче белгечлеге ала. Төрекмәнстан Фәннәр академиясенең Тарих институтында эшли башлагач, Совет армиясенә алына. Әфганстан җирендә дүрт елга якын гомерен уздыра. Үзләренең частьләре белән элемтәсез калып (рацияләре сафтан чыга), тугыз тәүлек камалышта булып та, безнең гаскәрләрнең автоколоннасы үтәсе юлга дошманнарны җибәрмәгәннәре өчен, төркем командиры өлкән лейтенант Альберт Борһанов «Батырлык өчен» медаленә лаек була. Күп кенә башка сугышчан операцияләрдә катнашканы өчен СССР Верховный Советы Президумы Указы нигезендә бирелгән Мактау грамотасы, «Рәхмәтле Әфганстан халкыннан», совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруга 25 ел тулу уңаеннан истәлек медальләре белән бүләкләнә. Армия хезмәтеннән соң, Урта Азия, Уралда археологик эзләнүләр буенча зур тәҗрибә туплаган галим Татарстанга күчеп кайта.

Танылган археолог Альберт Борһанов исеме күпләргә таныш. Ул – 440тан артык фәнни хезмәт, шул исәптән 36 монография һәм китап авторы. Утыз җыентыкның төзүчесе һәм фәнни редакторы, 6 уку ярдәмлеге авторы. Россия табигать фәннәре академиясенең Идел-Урал үзәге «Археология һәм Антропология» бүлеге җитәкчесе.

Ул, фәнни эшчәнлеге белән бәррәттән, Татарстанның Яшел Үзән, Биектау. Саба, Теләче, Балтач, Кукмара, Арча, Әлки,



■ Ж.Камалов (Борһановның бабасы).

Бөгелмә, Ютазы, Азнакай районнарында археологик казу эшләрен башлап җибәрде. Шунысы куанычлы, бу эшләргә ул шушы төбәкләрдә яшүче тарих укытучыларын, укучыларны да катнаштырып, аларны да фәнни эзләнүләр юлына этәрә. Соңыннан шул төбәкнең тарих һәм археология проблемалары буенча конференцияләр уздыра, монографияләр әзерләп бастыра. Анда, Казан галимнәре белән бәррәттән, якын-тирә районнарда яшәүче тарих белән кызыксынучылар, студентлар, мәктәп укучылары да бик теләп чыгыш ясый. Гомумән, Альберт әфәнде хәзерге вакытта бигрәк тә Казан арты районнарын археологик җәһәттән нигезле өйрәнүче тәҗрибәле галимнәребездән санала. Ул, 1998 һәм 2001елларда археологик казу-эзләнү эшләре вакытында Казан ханлыгы чорына караган Өтернәс шәһәрлеге калдыкларын өйрәнеп, Саба районы тарихын республикага танытты.

Соңгы елларда галим Кырымда, Төркиядә, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Казахстан, Иран, Румыния, Венгрия дәүләтләрендә үткән халыкара конференцияләрдә, кайбер симпозиумнарда, Татарстан вәкиле буларак, төрки халыклар тарихына кагылышлы докладлар ясый, бүгенге Татарстан халкының тарихи-мәдәни тормышы белән таныштыра. Бу кылган эшләре белән бәррәттән, автор Россия территориясендәге һәм кайбер чит илләрдә эшләүче фәнни академик берләшмәләрдә әгъза булып тора, аларның эшендә дә катнашырга вакыт таба.

Татарстанда югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә үзенең лаеклы өлешен кертә, актив фәнни-тикшерену һәм җәмәгать эшләре алып бара. Менә шулай бабасы башлаган эшне лаеклы рәвештә дәвам итә ул.

***Редакциядән.*** *Альберт әфәнде безнең газета белән дә тыгыз элемтәдә тора. Күптән түгел без аны Татарстанның атказанган фән эшлеклесе исеменә лаек булуы белән дә котладык. Бүген без Альберт Әхмәтҗан улын һәм уку йортыбыздагы барлык иригетләрне Ватанны саклаучылар көне белән дә котлыйбыз.*

• Заман таләбе

# «Мөмкинлекләрне үзебез тудырыйк!»

Алинә САДЫЙКОВА

19 февраль көнне Казан федераль университеты юридик факультетының кайбер студентлары өчен үзенчәлекле дәрес үткәрелде. Аларга ЭЛСА студент-юристларның Европа ассоциациясен тәкъдир итү булды.

Нәрсә соң ул ЭЛСА? Әлеге студент-юристларның Европа ассоциациясе – үз эченә 32 000 студент һәм яшь юристларны туплаган бәйсез, сәяси һәм коммерцияле булмаган зур оешма. Ул 1981 елда 42 милли төркемгә бүленгән 300 юридик факультет базасында Европакүләм оешма буларак формалаша. Үз алдына максат куярга өйрәнергә, һөнәри сыйфатларны камилләштерергә, башка илләрдәге танылган юристлар эшчәнлеген өйрәнергә, халыкара хокукның нечкәлекләрен аңларга теләүчеләр өчен ЭЛСА «ишекләре» һәрвакыт ачык! Әгәр чит ил гражданнары яисә чит ил законнар җыелмасы белән эш итәргә туры килсә, бирердәге тәҗрибә сезгә ярдәмгә киләчәк.



Влад Михневский фотосы

Чараны КФУның юридик факультеты студент-юристларның Европа ассоциациясе белән берлектә оештырды. Гражданлык һәм эшмәкәрлек хокукы кафедрасы доценты Илсур Салихов кызыксынып килгән студентларга ЭЛСА әгъзасы – Ленара Климовская белән видеоэлемтә аша аралашу мөмкинлеге тудырды. Казан кызы Ленара – 3 курс аспиранты, хәзерге көндә Бельгиядә укый. Ул җыелган студентларга ЭЛСА турында тулы мәгълүмат бирде, аның структурасы һәм мөмкинлекләре турында сөйләде: «Мин инде күптән ЭЛСАны Казанда булдыру идеясе белән янам. Казан федераль университетының перспективалары һәм мөмкинлекләре бик зур. Уку йорты безгә административ һәм матди яктан ярдәм итәргә әзер. Безгә бары тик берләшергә һәм җиң сызганып эшли башларга кирәк!» – дип, Ленара студентларның кәефен күтәрде.

ЭЛСА – ул кызыклы һәм каршылыклы семинарлар, халыкара конференцияләр, модельле уеннар, студент-юритслар өчен һөнәри стажировкалар дигән сүз. Ленара Климовская сүзләренчә, хәзер иң мөһиме – Казанда әлеге оешманың нигезен салырга һәм эшли башларга кирәк.

Аралашу видеоэлемтә аркылы булуга карамастан, ул чын мәгънәсендә дискуссиягә әверелде. Студентлар кызыксындырган сорауларын яудырып кына тордылар. Кемнедер проектның матди хәле, кемнедер чараларда аралашу теле мәсьәләләре борчыды. Илсур Салихов сүзләренчә, әлегә Казан студентлары өчен ЭЛСАга керү бушлай, ә тел мәсьәләсенә килгәндә, гадәттә, катнашучылар инглиз телендә аралаша икән. Әмма аларның күбесе өчен бу тел шулай ук чит булып санала. Шуңа күрә, тел барьеры дигән әйбер һич комачауларга тиеш түгел, дигән фикердә тора юридик факультет доценты: «Берләшмә – студентларның үз инициативасы. Шулай булгач, барысы үз кулларыгызда. Мин сезгә алтын таулар вәгъдә итмим. Анда барыгызны да кабул итеп, чит илгә чакырачаклар дип тә әйтмим. Бары тик мөмкинлекләр булганда, үзезгезне сынап карарга өндим! Инде кайбер мәсьәләләрдә активрак булырга да вакыт җиткәндер! Бу очракта ЭЛСА һәм юридик факультет ныклы нигез булып торачак!»

Үзенең әгъзаларына тәкъдим иткән мөмкинлекләр белән танышып чыкканнан соң, студентлар ЭЛСА Казан локаль төркемен булдырырга кирәк, дигән нәтиҗәгә килделәр.

● Халыкара туган тел көне

# Белем белемгә тартыр!

Алинә САДЫЙКОВА

21 февраль – Халыкара туган тел көне. Шул уңайдан, укучыларыбызны Казан федераль университетында эшләп килә торган Казан халыкара лингвистик үзәге эшчәнлеге белән таныштырырга булдык.

Казан халыкара лингвистик үзәге (КХЛҮ) рәсми рәвештә ачылмаса да, ул инде эшчәнлеген күптәннән, 2007-2008 еллардан ук башлап җибәрде. Бу вакытта Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында Карьера үстерү үзәге булдырылды. Уку йортлары кушылгач, КДУның филология факультеты һәм әлеге үзәк берләшү нәтиҗәсендә, аерым структура барлыкка килде. Хәзерге вакытта ул Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының аерым структур бүлекчәсе санала.

2013 елда үзәк грант ота. Аның ярдәмендә ул яңа укыту-методик комплекс, заманча техника, җиһаз-әсбаплар белән тәэмин ителә: интерактив такталар, iPad планшетлары, ноутбук, компьютерлар. «Үзгәрешләргә инде иялләшеп беттек диярлек. Интерьерыбызны алыштырдык, матур итеп, заманча ремонт ясалды. Хәзерге вакытта соңгы эшләр – картиналарны урнаштырып бетерү белән шөгыльләнәбез», – дип сөенә үзәк җитәкчесе Гөлнара Садыйкова.

Казан халыкара лингвистик үзәге мәктәп укучылары, студентлар, укытучылар һәм төрле яшьтәге, төрле өлкәдә хезмәт куючы кешеләр белән эшли. Гомумән, ул биш проектны гамәлгә ашыра. «Центр притяжения» проекты чит илләр вәкилләрен рус һәм милли телләр белән кызыксындыруны арттыру, аларны үстерү, чит ил студентларын җәлеп итү максатын тормышка ашыра. Күпләр инде яратып өлгергән «Ана теле» онлайн-мәктәбе дә бу проектка карый. Рус теленә бәйле онлайн мәктәп булдыру ниятләре дә бар икән. «Бу күбрәк чит ил вәкилләренә йөз тотып эшләнәчәк. Без дә рус телен башкаларга тәкъдим итә белергә тиеш», – дип ассызыклый Гөлнара Садыйкова. Алга таба чит илләрдә дә татар теле үзәге булдыру планлаштырыла. Бу зур масштаблы проект Каюм Насыйри исемен йөртер дип фаразлана.

«Гражданин мира» проекты конкурентлыкка сәләтле чыгарылыш студентларын әзерләүгә йөз тота. Монда сүз программаларны интернациональләштерү турында бара, ягъни КФУның башка уку йортлары белән төзелгән килешүләре нигезендә уртак белем бирү модульләре булдырыла. Нәтиҗәдә, ике уку йортының студентлары бер дистанцион мәйданда берләшә. «Тиздән НьюЙоркка COIL SUNY проекты турында килешү төзергә барырга җыенабыз», – дип искәртте җитәкче. Күпләр ишетеп кенә түгел, ә үзләре дә катнашып караган халыкара сертификация дә әлеге проект кысаларында башкарыла. Кембридж университеты (инглиз теле), Гете институты (алман теле), Париж шәһәренең Сәүдә-сәнәгать палатасы (француз теле) тел имтиханнарын кабул итеп, сертификат тапшыралар.

Университетка сыйфатлы белемгә ия булган абитуриентлар кирәк. Шул нисбәттән мәктәп укучылары белән эшли торган «Поколение NEXT» проекты гамәлгә кертелә. Биредә шәкертләр үзләрен кызыксындырган телләр буенча Бердәм Дәүләт имтиханнарына әзерләнәләр. Монда, инглиз теле белән беррәттән, рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбиятыннан әзерлек дәресләре алып барыла.

Каршылыклы заманда яшәгәнлектән, без барыбыз да конкурентлыкка сәләтле булырга тырышабыз. Әтел – шул сәләтнең бер өлеше. Шуңа күрә хәзерге вакытта берничә тел белү – ул зарури әйбер.



«Преподаватель 2.0» проекты укытучыларны яңадан әзерләү белән шөгыльләнә. Фәнни-педагогик составыбызның тел компетенцияләрен арттыру максатын күздә тоткан бу курсларда Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов та тыңлаучылар рәтендә.

«Ноу хау» исемле проект дәүләти һәм муниципаль хезмәткәрләр, пенсионерлар, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең һәм башка категория вәкилләренең филология фәннәре буенча компетенцияләрен арттыру юнәлешендә эшли. Ремонт ясалган вакытта инвалидлар өчен махсус җайланмалар булдыру да гамәлгә кертелгән.

Шулай итеп, үзәк һәр категория вәкилләре өчен махсус курслар әзерләгән. Курсларның дәвамлылыгы да төрлечә: 3 еллык, 4 айлык, яңадан әзерләү кебекләре дә бар. Бүгенге көндә барысы 8 төркем оештырылган, якын киләчәктә тагын 4-5не ачарга исәплиләр. «Киләчәккә планнарыбыз бик зурдан. Актив рәвештә дистанцион форматтагы укытуны кертеп җибәрәсебез килә. Күпчелек аудиториябез – олы яшьтәгеләр һәм алар һәрвакыт бирегә килеп йөри алмыйлар. Заманча технологияләр безгә мондый ниятләрне тормышка ашырырга мөмкинлек бирә», – диде Гөлнара Садыйкова.

Рус, татар, инглиз, алман, француз, испан һ.б. телләрне яхшырак, төптәнрәк беләсегез килсә, Казан халыкара лингвистик үзәгенә рәхим итегез! Һәр илнең ачкычы – тел, телен белгән ил ачар. Бик күп илләрне ачарга язсын сезгә!

● Без кунакта

# Хезмәттәшлек күпере салынды

Әнвәр ХУҖИӘХМӘТОВ,
укыту һәм тәрбия методологиясе кафедрасы җитәкчесе, профессор

6-9 февраль көннәрендә КФУ доценты Надежда Ячина Мальтада Дж.Хопкинс ис. университетта үткәрелә торган педагогика фәннәре буенча VI Бөтендөнья конференциясендә катнашып кайтты. Шул ук вакытта аңа биредә стажировка узу мөмкинлеге дә бирелде.

Доцент «Европа университетларында, аерым алганда, Мальта университетында белем бирү үзенчәлекләре», «Югары импактфакторлы журналларда гуманитар блоктагы мәкаләләрне тиешле калыпка кертү», «Мәгариф технологияләре һәм аларның Европа университетларында кулланылышы» һ.б. темаларга багышланган семинарларда катнашты.

Хезмәттәшебезнең докладлары һәм презентацияләре педагогика фәннәре докторы, профессор, Казахстанның республикасының исеме мәктәбе җитәкчесе, география дәреслеге авторы Улжалгас Есназарованы аеруча кызыксындырган, шул сәбәпле, ул 28 мартта Казанда узачак Халыкара конференциядә катнашу теләген белдерде.

Мальтадагы конференциядә дөньяның төрле почмакларыннан җыелган 600ләп кеше катнашты. Чарада аралашу өчен, нигездә, инглиз теле кулланылды.

Хезмәттәшебезнең чыгышыннан соң, Канада, Тайвань, Казахстан, Төркия галимнәре Казан федераль университеты белән хезмәттәшлек итәргә теләкбелдергән. Надежда Ячина эшләгән презентациядән төрле илләрдән килгән яшь галимнәр КФУ, аерым алганда, Психология һәм белем бирү институты турында күп файдалы мәгълүмат алдылар. Тыңлаучыларны бигрәк тә чит телләрне укыту методикасына караган мәсьәләләр кызыксындырды.

«Мондый очрашулар күп проблемаларны тирәнрәк аңларга һәм аларны хәл итү юлларын интенсиврак эзләргә ярдәм итә. Әлеге сәяхәтебез вакытында без КФУның дә-




рес юнәлештә хәрәкәт итүен аңладык һәм анда эшләвебезгә горурлык тойгылары кичердек. Мондый абруйлы чарада катнашу мөмкинлеге тудырганнары өчен университет җитәкчелегенә рәхмәтебезне белдерәбез», – дип сөйләде Надежда Ячина (фотода).

Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО) карары буенча 21 февраль Халыкара туган тел көне буларак билгеләп үтелә.



# Туган телем – иркә гөлем!

Бангладеш дәүләте тәкъдиме белән 1999 елның ноябрендә ЮНЕСКО Генераль конференциясе, ЮНЕСКОга кергән илләр һәм Берләшкән Милләтләр оешмасы 21 февраль көнен Туган тел көне дип игълан итте. Беренче мәртәбә ул 2000 елның 21 февралендә Парижда ЮНЕСКО штаб-фатирында тантаналы рәвештә билгеләп үтелде.

Ни өчен Халыкара туган тел көне итеп 21 февраль билгеләнгән соң? Эш шунда: 1952 елның 21 февралендә Пакыстанда бангли теленә дәүләт теле статусы таләп итеп көрәшкән 5 студент үтерелгән була. Билгеле булганча, Пакыстанның көнчыгыш өлеше соңрак Бангладеш бәйсез дәүләтенә әйләнә.

ЮНЕСКО Халыкара Туган тел көнен билгеләп үтүне хуплап чыга. Чөнки бу оешма дөнья халыкларының матди булмаган мирасын саклау өчен көрәшә, традицион яисә халык музыкасын, биюләрен, гореф-гадәт һәм йолаларны, авыз иҗатын һәм җирле халыкларның туган телләрен саклап калу буенча зур эшчәнлек алып бара.

Җир йөзендә бүгенге көндә 6000 тел бар дип исәпләнә. Шулардан иң күп санлы кешеләр тарафыннан кулланыла торганы – кытай теле, бу телдә 1,2 млрд кеше сөйләшә, инглиз телендә – 478 млн, хинди телендә – 437 млн, испанда – 392 млн, рус телендә – 284 млн, гарәптә – 225 млн, португалда – 184 млн, француз телендә 125 млн кеше сөйләшә.

Таралыш тыгызлыгы ягыннан мондый саннарны китерергә мөмкин: 6000 телнең яртысы Азия-Тын Океан регионында кулланыла. Яңа Гвинея төбәгеннән исә 1000 тел чыккан дип санала.

Белгечләр киләсе йөз еллыкта барлык телләрнең 95проценты яшәүдән туктар дип фараз итә. Мәсәлән, бер ел эчендә 10 тел юкка чыга дигән фикер бар. Тел ягыннан аеруча чуар булган төбәкләрдә телләрнең юкка чыгуы бигрәк тә көчле. Африкада биш йөздән кимрәк кеше сөйләшә торган 200 тел барлыгы билгеле, Америка Кушма Штатларында һәм Канадада индеецларның 200 теле юкка чыгу алдында тора дип саныйлар. Бу процесслар аеруча Бразилиядә көчле. Көньяк-Көнчыгыш Азиядә 600-700 тел бар, шуларның кырыгы дәүләт ярдәменә мохтаҗ. Европа илләрендә 123 телдән тугызы юкка чыккан, егерме алтысы югалу алдында тора, тагын 38 телгә шундый ук куркыныч яный. Һәр халыкның туган теле – аның мәдәнияте, тарихи көзгесе. Татар теле – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе. Бу – туган телебез белен горурланырлык мөһим фактор. Телебезнең киләчәге дә безнең кулларда.

Күргәнебезчә, дөньяда бик күп телләргә бетү куркынычы яный. Тел юкка чыктымы, шул телдә сөйләшкән халык та юкка чыга дигән сүз, чөнки ул инде башка телдә сөйләшә башлый, шул телдәге мәгълүматны үзләштерә, ә аның үз бабаларының йөзләрчә ел үсеп формалашып килгән мәдәнияте тел белән бергә юкка чыга.

Уку йортыбызда студентлар 12 телдә белем ала. Татар, рус, инглиз, немец, француз, испан,гарәп, фарсы, төрек, кытай, япон һәм корея телен өйрәнүче күпме яшь белгеч гыйлем туплый. Галим-мөгаллимнәр фикеренчә, әле тагын студентлар өчен берничә тел өйрәнергә мөмкинлекләр ачылачак.

*«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы материаллары файдаланылды*

• Уңыш сере

# Халкыңнан мәдхия

Динара МИННЕКАЕВА

Фәнис Яруллин диюгә, күз алдына иксез-чиксез дәрья килеп баса. Әгәр ул арабызда булса, февраль аенда үзенең туган көнен билгеләр иде.



Фәнис абыебыз Яруллин турында мин тыныч күңел белән генә искә ала алмыйм. Аның исемен ишетүгә, йөрәк түрен ниндидер бушлык биләп ала, һава җитми башлый. Мин генә түгел, күпләр шундый халәт кичерәдер. Аның белән якыннан аралашып яшәгән кеше буларак, сагынам мин аны. Аның төпле киңәшләрен, шаяртуларын, ягымлы карашын, күтәренке кәефен сагынам.

Шушы көннәрдә генә Казан педагогия көллиятендә Фәнис Яруллин истәлегенә, аның узган ел ахырында дөнья күргән «Хәтер төпләрендә утлы күмер» көндәлекләр китабына багышланган кичә узды. Көллият студентларының бу чарага никадәр җаваплы әзерләнгәннәренә сокланып кайттым. Фәнис абыебызның шигырьләрен сәнгатьле итеп укыдылар, аның сүзләренә язылган матур җырларны башкардылар. Студентларның дәртле биюләрен карап, Фәнис абыебыз да сөенеп яткандыр. Ә ул чынлап та безнең арада булды. Түргә эленгән фотосурәттән серле генә елмаеп карап торды ул безгә.

Яраткан әдибебезнең безнең күңелләрдә булуы сөендерә. Аеруча яшьләрнең, булачак укытучыларның аның иҗатын өйрәнүе, киләчәк буынга тапшыруы – изге эш. «Сез иҗат иткән шигърият ул тулы мәгънәсендә туган халкыбызның, аеруча яшьләрнең җан азыгы, рухи таянычы, оптимистик өмет һәм ышаныч чыганагы. Илебезгә, халкыбызга, тормышка мәхәббәт белән сугарылган прозаик һәм драматик әсәрләрегез дә талантлы әдәби әсәрләр генә түгел, көчле рух һәм сыгылмас ихтыяр җимеше булу белән кыйммәт», – дип язган аңа зур бәя биреп беренче президентыбыз Минтимер Шәймиев.

***P.S.*** Берничә ел элек Фәнис Яруллин үзенең көндәлекләреннән өзекләрне «Казан утлары» журналында бастырган иде, ул чакта күпләр аңа дәвамын күрербезме, дип мөрәҗәгать иткән. Көндәлекләрен бер тышлыкка туплау уе шул чакта туган. «Хәтер төпләрендә утлы күмер» исеме астында бу китапны ул үзе әзерләп, кереш сүзен яза, әмма менә нәшер итәргә өлгерми. Язучының тормыш иптәше Нурсөя апа Фәнис Яруллинның соңгы васыяте булып калган әлеге китапны эшләтеп бетереп, үз акчасына бастырды. Китапны безнең редакциядән алырга мөмкин.

**Шул китапны бер сулыш белән укып чыккач, ветеран укытучы Гәүһәр Әхмәдуллина язган шигырьне тәкъдим итәбез.**

*Курыкмадың, туры сүзең әйттең,*
*Кем тыя соң хак сүз сөйләүне?*
*Бүтәннәр әйтергә көч тапмагач,*
*Синең йөрәк шуңа түзәрме?*

*Сау чагыңда яныңа да килми,*
*Көнләшүдән йөзе куырылыкан*
*Олпат-олпат ирләр сөйли хәзер,*
*«Мин бит аңа иң күп булышкан».*

*Йөрәкләреңтүздe, сыкрый-сыкрый,*
*Зарланмадың, һәрчак көр булдың.*
*Аллаһ биргән нинди сабырлыклар,*
*Ахры син дөньяда бер булдың.*

*Халык язучысы шундый булсын икән,*
*Сиңа тиңнәр булырмы тагын?*
*Кылдан нечкә күңел моңнарыңны,*
*Түкми, чәчми саклар татарың.*

*Сине укып үсте бөтен мәктәп,*
*Ата-аналар чиксез рәхмәтле.*
*Сөйләннәргә тезгән энҗе кебек,*
*Сеңдердең һәркемгә әхлакны.*

*Халкымның Син булдың йөз аклыгы,*
*Вөҗданы һәм аның иманы.*
*Җан көзгесе, татар милләтенең*
*Ышанычлы рухи маягы.*

*Җәннәтләрдә ят син , Фәнис абый,*
*Иҗатыңа халкым баш ия.*
*Исемең яшәр мәңге йөрәкләрдә,*
*Бездән изге дога, мәдхия.*

• Яшьлек-яңарыш

# Шигырь дулкынында

Ильмира КАМАЕВА,
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

13 февраль көнне шәһәребезнең «Театральное» кафесында Татар Шигъри Слэмы узды. Чара 21 февраль – Халыкара туган тел көнenә багышлап, быел инде икенче мәртәбә уткәрелде.



Слэм – шигъри көч сынашуның популяр форматы. Һәр катнашучы үзе иҗат иткән әсәрен башкалар хозурына тәкъдим итә. Биредә шигырьләрнең сыйфаты гына түгел, ә аларны башкару осталыгы да зур роль уйный. Катнашучылар, ике турда чыгыш ясап, үзара көч сынаша. Чыгышларны исә залга җыелган тамашачы бәяләп бара.

Быелгы Слэмда 12 катнашучы чыгыш ясады. Һәрберсе тамашачыга үз иҗат җимешләрен кызыклы итеп тәкъдим итәргә тырышты. Җиңүче исемен алу өчен, икенче турда 6 катнашучы көч сынашты. Тамашаны «Ялкын» журналы баш мөхәррире, шагыйрә Йолдыз Миңнуллина алып барды. Татар әдәбияты, мәдәнияте һәм, гомумән, татар дөньясына битараф булмаган яшьләрнең бер мәйданга җыелулары, шушындый рухтагы кызыклы кичәләр оештырылуы бик шатлыклы күренеш.

Оештыручыларның берсе – «Идел» яшьләр үзәге директоры Ләйсән Сафина – мондый чараларның киңрәк колач алуын тели. «Кызыклы формат! Яшь татар язучыларының гел бергә җыелып, аралашып иҗат итүләрен телим. Кулдан-кулга йөреп укыла торган әсәрләр күбрәк язылсын иде», – дип, үз фикере белән уртаклашты ул.

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты Ләйлә Хәбибуллина әлеге чарада икенче тапкыр катнаша икән: «Узган елны, беренче тапкыр булгангамы, биредәге атмосфера шундый тылсымлы иде. Ничегрәк булыр икән дип, ниндидер серле халәттә утырдым. Быел андый тәэсирләр булмаса да, «Иделем акчарлагы» бәйгесе конкурсантлары катнашуы бик куандырды. Чыгышлар да узган елгыга караганда төрлеләндерелгән, тере. Гомумән, бары уңай тәэсирләр генә калды миндә. Лауреатлар һәм барлык катнашучыларга сокланып утырдым. Татарларда мондый шигъри батл булуына куанам гына. Әлеге бәйгенең казанышлары, яңа ачышлары алда дип саныйм. Яшь шагыйрьләр, гомумән, татар әдәбияты Татар Слэмы белән берлектә яңа үсеш алсын иде дигән теләктә калам!»

Бәйгедә җиңүчеләр булуы – гадәти күренеш. Икенче Татар Слэмында 1 нче урынга Буа районы Күл-Черкен авылы кызы Лилия Сәләхетдинова лаек булды. Лилиянең тумыштан мөмкинлекләре чикләнгән. Кыз кечкенә дә төш кенә булса да, бөтен җиргә өлгерә! Күзләрендә яшәү дәрте балкып торучы бу туташтан барыбызга да үрнәк алырга кирәк! «Үткән ел Шигъри Слэм уздырылу турында ишетеп белгән идем, Казанда яшәмәвем сәбәпле, катнаша алмадым. Быел исә мөмкинлек чыкты да катнашырга булдым. Бу бәйгенең башкаларыннан аермасы шунда: бәяләүчеләр үзебезнең чордашлар, каләм тибрәтүче яшьләр. Урын алырмын дип уйламаган да идем, бу көтелмәгән вакыйга булды. Киләчәктә дә шулай аралашып яшәсәк иде», – дип, кичәдән алган тәэсирләре белән уртаклашты Лилия. Узган елгы Слэмнан аермалы буларак, быел бәйгедә өч җиңүче билгеләнде. Шулай итеп, икенче һәм өченче урыннарны Эльнар Байназаров һәм Ильмира Камаева (*фотода*) бүлештеләр. Җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Чара композитор Эльмир Низамов, җырчы кызчык Сәйдә Мөхәммәтҗанова һәм Исмаил чыгышлары белән үрелеп барды. Узган елгы Слэм оештыручылары Гүзәл Низамова һәм Язгөл Сөләймановага быел «Идел» яшьләр үзәге, «Татар балы» проекты да кушылган. Слэмның аудиториясе киңәя. Димәк, әле бары да алда!

• Безнең канат



КФУның И.Н.Лобачевский ис. лицей шәкертләре «Яңа Гасыр» каналында бара торган «Тамчы шоу» интеллектуаль күңел ачу уенында көч сынашып кайттылар. 8 сыйныф укучылары, ярышта катнашу теләген белдереп, «Татар кызлары» һәм «Татар егетләре» командаларына бүленделәр. Мондый тапшыруда беренче тапкыр катнашуларына карамастан, шәкертләр дулкынлануларын, борчылуларын җиңеп, бик яхшы чыгыш ясадылар. Укучылар әзерлек процессына җаваплы караганнар: күп санлы китап-журнал укыганнары әллә каян сизелеп тора. Алай гына да түгел, алар үзләрен башка фән өлкәләрендә дә белемле булуларын һәм, шул рәвешле, И.Н.Лобачевский ис. лицейда бик төпле һәм акыллы балалар укуын дәлилләделәр. Ә бәйгедә кайсы команда җиңү яулаганын якын киләчәктә ТНВ каналыннан карап белә алачаксыз!

• Син+Мин=БЕЗ!



Экология һәм география институты җитәкчелеге КФУ профессор укытучылар һәм хезмәткәрләренең «Сәламәт бул!» Спартакиадасында актив катнашкан О.А.Бунаков, М.В.Исаева, Б.М.Эйдельман, Н.К.Габдрахманов, С.К.Губеева, Д.В.Тишин, С.Р.Газизова, Д.Ф.Садретдинов, И.М.Гасанов, А.Р.Нуртдинов, Р.Ш.Фархуллиннарга ихлас рәхмәт сүзләре житкерә һәм аларга нык сәламәтлек, гаилә бәхете, яңа җиңүләр тели.

Метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасының өлкән укытучысы, география фәннәре кандидаты Марина Исаеваны КФУ хатын-кызлары арасында 1 нче урын, Идел буе районы буенча вузара ярышларда 3 нче урын алуы белән тәбрикли.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.